РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Шереметьевского сельского поселения
Нижнекамского муниципального
района

423560, Нижнекамский район,
с. Шереметьевка, ул.Октябрьская площадь, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама
муниципаль районы
Ширәмәт авыл җирлеге
Советы

423560, Түбән Кама районы,
Ширәмәт авылы, Октябрь мәйданы урамы, 15

тел./факс (8555) 33-02-44 электронный адрес: Sheremetevskoe.Sp@tatar.ru, сайт: www. sheremetevskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.11.2023 ел № 24

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2018 елның 23 июлендәге 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендә 78 статьясының 1 пунктындагы икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Ширәмәт авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2018 елның 23 июлендәге 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2.2 пунктында:

«объектлар белән» сүзләрен «һәм (яки) объектлар белән» сүзләренә алыштырырга;

«объектка туры килгән җир кишәрлегенә хокукка өлеше» сүзләрен «күчемсез мөлкәт объектына туры килгән җир кишәрлеге өлешләре» сүзләренә алыштырырга;

«һәм объектларга» сүзләрен «һәм (яки) объектларга» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карар 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

В.И.Никишин